| | |
|---|---|
| ГЛАВА КУШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.11.2021 ел Кошман ав. № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2021 елның 22 ноябренә 14 сәг 00 минутка Кошман авылы, Мәктәп ур, 31 йорт адресы буенча урнашкан Кошман төп гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2021 елның 23 ноябренә 10 сәг 00 минутка Кошман авылы, Мәктәп ур, 39 йорт адресы буенча урнашкан Кошман балалар бакчасы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2021 елның 24 ноябренә 10 сәг 00 минутка Кошман авылы, Үзәк ур, 16 йорт адресы буенча урнашкан Кошман авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 2021 елның 25 ноябренә 10 сәг 00 минутка Кошман авылы Сәгыйди урамының 43 нче номерлы йорты янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.
5. 2021 елның 26 ноябренә 13 сәг 00 минутка Кошман авылы, Сәгыйди ур, 59 йорт адресы буенча урнашкан ШЭ Гафиятуллин С.Л.ның “Алинә” кибете бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының бишенче этабын билгеләргә.

6. 2021 елның 27 ноябренә 10 сәг 00 минутка Кошман авылы, Үзәк ур, 16 йорт адресы буенча урнашкан Кошман авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләре буенча гражданнар җыенының алтынчы этабын билгеләргә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Кошман авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:

-урамны яктыртучы утларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

-буаны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- кое ремонтлау һәм аның тирәсен төзекләндерү, моның өчен материаллар сатып алу

- торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;

б)авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- су башняларын лицензияләү буенча әзерлек эшләре;

в)авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә».

« РИЗА» «КАРШЫ»

7. Кошман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырырга (http://pravo.tatarstan.ru). Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://kushman-kaybici.tatarstan.ru.

8. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәргәндә Кошман авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышлы (COVID – 19) авыру очракларын кисәтү һәм таратуга каршы профилактик, санитар-эпидемик чараларның үтәлешен тәэмин итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык Л.Р. Сафина